**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур авылы КАРАР

«30» октября 2019 г. № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Бакча урамы, 5 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында Бакча урамы буенча1-38нче, Кыр урамы буенча 2-29нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

2) Урамнарны яктырту (ремонт, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Октябрина авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы В.В.Охототникова